СОВЕТ
УРНЯКСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Лесная, д. 44А, п.Урняк,
Арский муниципальный район, 422019

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ҮРНӘК
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Урман урамы, 44А йорты, Үрнәк авылы,
Арча муниципаль районы, 422019

Тел. (84366)51-4-93, факс (84366)51-4-93. E-mail: Urn.Ars@tatar.ru

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Башлыгы**

**КАРАРЫ**

**19 октябрь 2020 ел** **№9**

**Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлеге Иске Төрнәле авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль Үрнәк авыл җирлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Башлыгы Карар бирде:

1. Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлеге Иске Төрнәле авылында Иске Төрнәле авылы, Мәктәп урамы, 46 нчы йорт адресы буенча урнашкан Иске Төрнәле авыл клубы бинасында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча 2021 елның 06 ноябренә 10 сәгать 00 минутта халык җыенының беренче этабын билгеләргә.

2.Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлеге Иске Төрнәле авылында Иске Төрнәле авылы, Мәктәп урамы, 46 нчы йорт адресы буенча урнашкан Иске Төрнәле авыл клубы бинасында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча 2021 елның 06 ноябренә 11 сәгать 00 минутта халык җыенының икенче этабын билгеләргә.

3.Торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген бүлүне территория буенча башкарырга:

1 нче этап: Мәктәп, Пионер урамнарында яшәүчеләр;

2 нче этап: Комсомол урамнарында яшәүчеләр.

4. Халык җыенына чыгарылучы түбәндәгемәсьәләне расларга:

«Сез 2021 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлеге Иске Төрнәле авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 150 сум тәшкил иткән, 1 нче төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан, көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, 300 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча тубәндәге эшләргә юнәлдеру белән килешәсезме:

1. Юл-урам челтәренә тигезләү катламы ясау:
Комсомол урамы – 100 м.

2. Зиратны чистарту һәм тәртипкә китерү өчен үләнчапкыч һәм бензин пычкысы сатып алу.

3. Пионер урамыннан Мәктәп урамына кадәр җәяүлеләр күпере урнаштыру.

4. Торак пунктларда кышкы чорда җирле әһәмияттәге юлларны кардан чистарту.

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә.

“ӘЙЕ” “КАРШЫ”

5. Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлеге Иске Төрнәле авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы итеп Үрнәк авыл җирлеге башкарма комитетын билгеләргә.

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасының Рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга һәм халык күпләп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендына түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: Татарстан Республикасы, Арча районы, Иске Төрнәле авылы, Комсомол урамы, 64 нче йорт.

7. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Үрнәк авыл җирлеге башлыгы В.Р.Габделхаков